ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 58 от «28» 01 2019 года

**"Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында»**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм җирләү эше турында» 8-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 24 гыйнварындагы «2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 32 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2019 елның 1 февраленнән Спас муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 26 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә бирелә торган тарифларны раслау турында» 32 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е. А. Афоньшинага йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
2нче Кушымта
№ 58 от «28» 01 2019г.

**01.02.2019 елдан**
**Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында**
**җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә**
**күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе**

| **Хезмәтләрне исеме** | **Хезмәтләрнең бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | 118,92 |
| 2. Мәетне киендерү | 133,80 |
| 3. Табут, җирләү өчен башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 2542,11 |
| 4. Мәетне зиратка алып бару | 445,99 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2705,65 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |